# М.Фәйзинең 135 еллыгы: дөньяга әдәби моң биреп

## Танылган драматургның юбилее уңаеннан иҗади сайт тәкъдим итү



**Фирүзә Ибраһимова,**
11 сыйныф укучысы, Яңа Чишмә районы Шахмай урта мәктәбе



**Гыйльманова Кадрия Кыям кызы,**
югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

2026



## Проект эшемнең максаты:

Нәселе Яңа Чишмә районыннан башланган музыкаль драмага нигез салучы Мирхәйдәр Фәйзинең тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу.

## Проект эшемнең бурычлары:

- М.Фәйзи турында мәгълүмат туплап, яшьтәшләрем өчен кызыклы булырдай сайт эшләү;
- Танылган драматург исемен йөрткән Шахмай авылы музеена сәяхәт кылу;
- Әдәбият дәресләрендә куллану өчен кызыклы видеосюжет төшерү;
- Яңа Чишмә районыннан чыккан профессиональ язучылар турында мәгълүматлар туплау.

**Структурасы түбәндәгедән гыйбарәт:**

Кереш өлештә эшебезнең темасы, максаты, бурычлары билгеләнде, М.Фәйзи турында кыскача мәгълүмат бирелде.

Төп өлештә: “Безнең мирас” журналында тәрҗемә ителеп чыккан кулъязмаларыннан өзекләр өйрәнелде, “М.Фәйзи исемендәге Шахмай авылы музее”нда мәгълүмат тупланды, Мирхәйдәр Фәйзинең Шахмай авылы белән бәйләнеше күрсәтелде, Яңа Чишмә районыннан чыккан профессиональ язучылар турында кыскача язылды.

Йомгаклау өлешендә тупланган мәгълүматны файдаланып сайт эшләнде: видеосюжет төшерелде, тест ясалды.

**Тикшеренү объекты** итеп М.Фәйзи иҗаты алынды.

Проект эше барышында тикшеренү, эзләнү, чагыштыру, күзәтү, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау **алымнары һәм ысуллары** кулланылды.






## Син гөлме? Милләт бакчасының Гөлләренә баскан былбылмы?

Мирхәйдәр Фәйзи — татар әдәбияты классигы, фольклорчы, шагыйрь, татар әдәби музыкаль драмасына нигез салучы әдип. Аның тормыш йомгагы 1891 елның 1 ноябрендә Орск өязе Күкшел авылында тәгәри башлый. Иҗат юлы исә “Хөсәения” мәдрәсәсендә укыганда башлана: тәүге мәкаләсе 1908 елның 1 гыйнварында “Чүкеч” журналының баш битендә дөнья күрә, алга таба иҗат җимешләре “Бәянелхак”, “Шура”, “Әльихлас” һәм башка басма матбугатта басылып чыга. Ул үзенең кыска иҗат дәверендә 16 оригиналь сәхнә әсәре яза, 7 пьеса тәрҗемә итә, халык җырлары җыентыгын төзи, 200 дән артык шигырь, дистәләгән хикәя яза, 70 көндәлек дәфтәре калдыра.

# Мирхәйдәр Фәйзи - күренекле язучы, драматург




Шахмай авылы музеенда М.Фәйзинең шәхси әйберләре, китаплары, драматургның тәрҗемә ителеп “Безнең мирас” журналында басылып чыккан кулъязмалары бар. Аларның һәркайсы белән музей мөдире таныштырып чыкты. Проект эше барышында тупланган мәгълүмат ярдәмендә сайт эшләнелде (скриншоты беркетелгән), әдәбият дәресләрендә куллану өчен видеосюжет төшерелде.

Алар белән шушы сылтама аша яисә QR-код ярдәмендә кереп танышып, файдаланып була. Биредә башка кызыклы материаллар да тупланган.

Сылтама: https://inheritance.turbologoru.site/

# М.Фәйзинең 135 еллыгы: дөньяга әдәби моң биреп








## Тупланган белемнәрне ныгыту өчен тест

Алдарак әйтелгән видеосюжетны карагач, драматургның биографиясе белән танышкач, М.Фәйзи тормышы һәм иҗаты турында тупланган белемнәрне ныгыту өчен сайт кунакларына 8 сораулы онлайн-тест (скриншоты беркетелгән) үтәргә тәкъдим ителә. Сораулар беренче карашка гади: “Мирхәйдәр Фәйзинең туган авылын сайла”, “Ничә драма әсәре иҗат итә ул?”, “Кайсы әсәре анарга танылу алып килә?” һ.б. Әмма бүгенгесе көндә 19 кулланучының 6сы гына, ягъни 30% максималь баллга эшләде.

*Алдагы слайдта әйтелеп узганча, сайтка шушы сылтама, яисә QR-код ярдәмендә узып була.*

Сайтка сылтама: https://inheritance.turbologoru.site/

# Яңа Чишмә - күренекле шагыйрь-язучыларның туган нигезе



**Шамил ШӘЙДУЛЛИН**

1939-2008, Сөлчәбаш авылы. Детектив әсәрләр авторы, 10 китабы дөнья күрде



**Җәүдәт ЮНЫС**

1960 елда Сөлчәбашта туа. Машинасын сатып “Ияләр ни дияр...” китабын чыгара



**Нәкыйп ГАЛИМОВ**

1954 елда Шахмай авылын-да туа. Шигырьләр, җырлар иҗат итә, 2 китап авторы



**Лилия ФӘТТАХОВА**

1972 елда Чаллы Башы авы-лында дөньяга килә. ТР Язучылар берлеге әгъзасы

Шулай ук **Рәүф ЮНЫСОВ, Минниса НӘБИУЛЛИНА, Зәйнәп ХӘБИБУЛЛИНА, Зәкия ГАРИФУЛЛИНА, Гөлия ГЫЙЛЬМАНОВА һ.б.**



**Миләүшә ХАЛИКОВА**

1960 елда Акъяр авылында туа. Бүгенгесе көндә дә ак-тив иҗат итә, шагыйрә

## Татар әдипләрен бергәләп өйрәник

Мирхәйдәр Фәйзи мирасы – безнең өчен чиксез хәзинә. Бу проект аша без аның тормыш юлына һәм иҗатына бер генә күз салып калмадык, ә яңа буын өчен кызыклы һәм файдалы мәгълүмат чыганагы булдырырга тырыштык. Безнең сайт, видеосюжет һәм тест – әдипнең иҗатын өйрәнүдә ярдәмлек кенә түгел, ә яшьләрне әдәбиятка якынайту, тарихыбызга мәхәббәт уяту алымы да.

Шунысын да әйтергә кирәк, Яңа Чишмә районы җире талантларга бик бай. Безнең төбәктән чыккан күренекле язучыларның буыны дәвам итә, бу исә киләчәктә дә әдәбиятыбыз яңа исемнәр белән баетылачак дигән сүз.

Бу проект – бары тик беренче адым гына. Киләчәктә дә Мирхәйдәр Фәйзинең иҗатын тирәнтен өйрәнү, аның турында яңа мәгълүматлар табу һәм аны халыкка җиткерү өстендә эшләү теләге белән янабыз. Чөнки Мирхәйдәр Фәйзи – ул безнең горурлыгыбыз, безнең мирасыбыз!